КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 26 март г.Казань № 275

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче; 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче; 2023 ел, 14 апрель, 462 нче; 2023 ел, 5 август, 946 нчы; 2023 ел, 6 октябрь, 1252 нче; 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче; 2024 ел, 10 май, 316 нчы; 2024 ел, 6 август, 623 нче; 2024 ел, 4 сентябрь, 724 нче; 2025 ел, 12 апрель, 222 нче; 2025 ел, 22 май, 347 нче; 2025 ел, 2 июнь, 392 нче; 2025 ел, 2 август, 559 нчы; 2026 ел, 16 гыйнвар, 12 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.3 пунктчада:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«начар метеорологик шартлар чорында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны җайга салу чараларын үткәрүне оештыра;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«начар метеорологик шартлар буенча гомуми фараз кергәндә хуҗалык һәм (яки) башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү чараларын үткәрергә тиешле юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә мәгълүмат бирүне тәэмин итә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«үз компетенциясе чикләрендә атмосфера һавасын саклау буенча Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка гамәлләрне гамәлгә ашыра.»;

3.3.8 пунктчаның бишенче абзацында «азайту» сүзен «киметү»сүзенә алмаштырырга;

5.2 пунктның тугызынчы абзацында «билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куя» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп гамәлгә куя» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1194 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 16 сентябрь, 793 нче; 2025 ел, 2 август, 559 нчы; 2026 ел, 13 гыйнвар, 5 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, VII бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.14 – 7.15 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«7.14. Юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан төп производстволарның технологик процесслары, әйләнә-тирә мохитне пычрату чыганаклары тасвирнамәләре, пычраткыч матдәләр чыгаруларны, агызуларны зарарсызландыру буенча техник чаралар тасвирнамәләре, җитештерү һәм куллану калдыкларын файдалану, зарарсызландыру һәм урнаштыру технологияләре үзгәрү турында белешмәләр бирелүгә бәйле рәвештә, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объект турында исәпкә алу белешмәләрен актуальләштерү турында мәгълүмат, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объект категориясе үзгәрү турында мәгълүмат булмаганда, хисап чоры өчен юридик зат, индивидуаль эшмәкәр тарафыннан әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен кертелгән түләү күләмен, узган хисап чоры белән чагыштырганда, 30 һәм аннан күбрәк процентка арттыру яки киметү.

7.15. Юридик затның, индивидуаль эшмәкәрнең Интернет челтәрендәге сайтында һәм (яки) һәркем файдалана торган башка мәгълүмат системаларында әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган эшчәнлек башланган вакыттан алып алты ай эчендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектны

дәүләт исәбенә кую турында заявка булмаганда әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында мәгълүмат урнаштыру.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче; 2022 ел, 25 октябрь, 1137 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 2 сентябрь, 714 нче; 2026 ел, 13 гыйнвар, 5 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, VII бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.10 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«7.10. Үзара хезмәттәшлек итмичә контроль (күзәтчелек) чаралар үткәргәндә, «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматларын анализлаганда, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән яки физик затлардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контрольдә тотылучы затның норматив хокукый актлар нигезендә Министрлыкка мәҗбүри тапшырылырга тиешле мәгълүматны элегрәк тулы һәм (яки) дөрес тапшырмавын күрсәтә торган белешмәләр кергәндә, узган хисап чоры белән чагыштырганда, контрольдә тотылучы затның норматив хокукый актлар нигезендә Министрлыкка мәҗбүри тапшырылырга тиешле хисаплылык һәм башка мәгълүмат белешмәләрендә 30 проценттан артыграк ачыкланган аерымлыклар.».

4. Бу карарның 1 пунктындагы дүртенче – җиденче абзацлары гамәле 2026 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин